ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«08»декабрь 2020 нче ел

**КАРАР**
№ 57

**«Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү турында карар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 222 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү турында карар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм рәсми порталда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Балтач шәһәр җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Д.Габдрахманов